**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6332**
**05.12.2019**

Башкарма комитетның «Муниципаль
ихтыяҗлар өчен җир участогын
кире алу турында» 2019 елның 14 июнендәге
3025 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын кире алу турында» 2019 елның 14 июнендәге 3025 номерлы карарының 2 пунктына (Башкарма комитетның 2019 елның 13 ноябрендәге 5832 номерлы карары редакциясендә) «Леонова Татьяна Вячиславовна» сүзләрен «Хорькова Татьяна Вячиславовна» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә:

1) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

2) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә, законда каралган тәртиптә, әлеге карарның күчермәсен әлеге карарның 1, 2 пунктларында күрсәтелгән кире алына торган күчемсез милек объектларына хокукы булган затларга җибәрергә;

3) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Яр Чаллы бүлегенә җибәрергә;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйzzзәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин